Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Сәпәй авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

Сәпәй авылы № 46 07 марта 2017 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Советы 2010 елның 10 ноябрендәге 8 номерлы “Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сәпәй авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарының хокукый актлары һәм норматив хокукый актлары проектлары норматив экспертиза коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибе турында"гы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сәпәй авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибенә үзгәреш кертү турында
29.02.2012 № 37 карар редакциясендә)

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Советы 2010 елның 10 ноябрендәге 8 номерлы “Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сәпәй авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарының хокукый актлары һәм норматив хокукый актлары проектлары норматив экспертиза коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибе турында"гы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сәпәй авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибенә (29.02.2012 № 37 карар редакциясендә) түбәндәге эчтәлекле 16 пункт өстәп, түбәндәге үзгәрешне кертергә:
«Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмә рекомендация характерында була һәм ул җибәрелгән Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сәпәй авыл җирлегенең җирле үзидарә органы тарафыннан аны алганнан соң 30 көн эчендә һичшиксез каралырга тиеш. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздырган гражданга яки оешманы карау нәтиҗәләре буенча, дәлилләнгән җавап җибәрелә (бәяләмәдә ачыкланган коррупциоген факторлар турында мәгълүмат булмаган очраклардан яисә ачыкланган коррупциоген факторларны юкка чыгару ысулы турындагы тәкъдимнәрдән тыш), анда коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләрен һәм (яисә) норматив хокукый актта яки норматив хокукый акт проектында ачыкланган коррупциоген фактор белән риза булмау сәбәпләрен исәпкә алу чагыла".
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлегенең законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча комиссиясенә йөкләргә.

Рәис Ф.Г. Галиева